Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы
“Түбән Мактама шәһәр тибындагы бистәсе” муниципаль берәмлеге
Түбән Мактама шәһәр тибындагы бистәсендә
гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы КАРАРЫ

29 ноябрь 2021 ел №1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, 2021 елның 13 ноябрендә 09 сәгать 00 минутта, 2021 елның 13 ноябрендә 10 сәгать 30 минутта, 13 ноябрендә 12 сәгать 00 минутта, 2021 елның 13 ноябрендә 13 сәгать 30 минутта, 14 ноябрендә 09 сәгать 00 минутта, 2021 елның 14 ноябрендә 10 сәгать 30 минутта, 14 ноябрендә 12 сәгать 00 минутта, 2021 елның 14 ноябрендә 13 сәгать 30 минутта, 20 ноябрендә 09 сәгать 00 минутта, 2021 елның 20 ноябрендә 10 сәгать 30 минутта, 20 ноябрендә 12 сәгать 00 минутта, 2021 елның 20 ноябрендә 13 сәгать 30 минутта, 21 ноябрендә 09 сәгать 00 минутта, 2021 елның 21 ноябрендә 10 сәгать 30 минутта, 21 ноябрендә 12 сәгать 00 минутта, 2021 елның 21 ноябрендә 13 сәгать 30 минутта, 27 ноябрендә 09 сәгать 00 минутта, 2021 елның 27 ноябрендә 10 сәгать 30 минутта, 27 ноябрендә 12 сәгать 00 минутта, 2021 елның 27 ноябрендә 13 сәгать 30 минутта узган гражданнарның этаплы җыен нәтиҗәләре нигезендә «Сез 2022 елда Түбән Мактама ш.т.б. территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән (1 төркем инвалидларыннан, балачак инвалидларыннан, 18 яшькә кадәрге 3 һәм аннан күбрәк баласы булган күп балалы гаиләләрдән, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм аларга тиңләштерелгәннәрдән, бөек Ватан сугышында катнашучыларның толларыннан, хәрби хәрәкәтләрдә катнашучылар, РФ Коралллы Көчләре сафларында хезмәт итүче гражданнардан тыш) 400 сум күләмендә үзара салым кертергә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтүгә: юлларны, урам утларын, балалар һәм спорт мәйданчыкларын норматив хәлгә китерү, сметалар төзү, техник күзәтчелек үткәрү һәм җирлек милкенә рәсмиләштерү өчен түләү?» соравы буенча грждbackannар җыены беркетмәсе төзелде:

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 7474 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 3961 кеше, бу 53% тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

гражданнар җыенында катнашучыларның 2235 «РИЗА» позициясе өчен тавыш бирде; гражданнар җыенында катнашучыларның 1726 «КАРШЫ» позициясе өчен тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Түбән Мактама ш.т.б. торак пунктында гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыенының нәтиҗәләре - чынбарлыкка туры килә.

2.Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы “Түбән Мактама шәһәр тибындагы бистәсе” муниципаль берәмлеге Түбән Мактама шәһәр

тибындагы бистәсендә яшәү урыны буенча теркәлгән, даими яшәүче булган һәр балигъ булган кешедән үзара салым средстволарын 2022 елда 400 сум күләмендә кертергә.

3. Җыелган үзара салым средстволарын җирле әһәмияттәге түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерергә: юлларны асфальтлау, урамнарны яктырту, энергия саклаучы лампалар, яктырткычлар урнаштыру, тротуарларны ремонтлау, балалар һәм спорт мәйданчыкларын урнаштыру, һәйкәлләрне, зиратларны карап тоту, Мактаминка елга яр буен төзекләндерү, проект-смета документациясен эшләү өчен түләү, күрсәтелгән эш төрләренә техник күзәтү үткәрү һәм авыл җирлеге милкенә рәсмиләштерү өчен түләү.

4. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетысында бастырырга, Түбән Мактама шәһәр тибындагы бистәсе территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында халыкка игълан итәргә, «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU), Әлмәт муниципаль районы сайты «Интернет» челтәрендә урнаштырырга.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче Р.А. Бәдретдинов